КПРФ

Татарстан Республикасы
# КОММУНИСТЫ

4 мартта Зюгановны сайлыйбыз!

«КПРФ» политик партиясе информацион бюллетене. 2012 ел, 10 февраль

# КПРФтан һәм халык-патриотик көчләрдән Президентлыкка кандидат Г.А. ЗЮГАНОВның Россия гражданнары каршындагы йөкләмәләре
## (сайлау алды программасы)




Власть һәм милекне – халыкка!

**Ватандашларым! Илебез өчен гаять авыр бу чорда мин Сезгә мөрәҗәгать итәм. Соңгы 20 елда Россия зур югалтулар кичерде. Ил үлеп бара. Анда һәлак булмый калган авыллы бер генә почмак та юк. Харап ителмәгән предприятиеләре сакланган бер генә шәһәр дә юк. Гражданнарның күпчелегенең тормыш дәрәҗәсе түбәнәйгәннән түбәнәя бара. Фәнни-техник яктан артта калганлык та һәлакәткә тиң дәрәҗәгә җитеп килә. Уникаль мөмкинлекләр кулдан ычкындырылды. Алда безне хәзер ике генә юл көтә: я тиз арада күтәрелә башларга, яисә төпкә тәгәрәргә. Вакыт кичекмәстән үзгәрешләр таләп итә.**

## Илне коткару хакына

Капитализм бөтен дөньяда кычкырып торган хәерчелек, каршылыклар һәм сугышлар, мәдәни деградация һәм экологик проблемаларны ныклы үҗәтлек белән даими төстә тудырып кына тора. Аның банкротлыкка чыккан системасы дөньяны тагын көчле кризиска китереп терәде, безнең илебез дә шуның корбаны булды.

**Булган проблемаларның бөтен кискенлеген һәм авырлыгын аңлаган хәлдә, мин, Геннадий Зюганов, Россия язмышы өчен җаваплылыкны үз өстемә алырга тулысынча әзермен.** Президент булып сайланган очракта, мин халык ышанычына таяна торган Хөкүмәтне патриот-профессионаллардан төзүне гарантиялим. Ул, төрле партияләр вәкилләрен һәм партиясезләрне дә кертеп, коалицион нигездә төзеләчәк. Хөкүмәтебезнең яңа башлыгы политик пропаганда белән түгел, ә илебез хуҗалыгын оештыру эшләре белән шөгыльләнәчәк.

**Башкарма властьның барлык эше дә Россия өстенә ябырылган биш төрле афәтне җиңеп чыгу максатына буйсындырылачак:**

*– коточкыч дәрәҗәгә җиткән социаль тигезсезлекне бетерүгә;*

*– демографик катастрофаны бетерүгә;*

*– чимал энәсенә утыртылган экономиканың таркалуын туктатуга;*

*– оборона тотуга сәләтсезлекне бетерүгә;*

*– рухи-әхлакый деградацияне туктатуга.*

**Дәүләт башында булганда, безнең команда түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:**

*– илебезнең милли һәм гражданнарның шәхси куркынычсызлыгын;*

*– экономик яктан түбән тәгәрәүдән тизләтелгән үсешкә күчүне;*

*– хәерчелекне һәм җәмгыятьнең деградацияләнүен җиңеп чыгуны;*

*– Россия халыклары дуслыгын ныгытуны;*

*– законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклауны.*

**Барлык үзгәрешләрне дә без халык файдасына һәм халыкның үзе белән бергә эшләячәкбез.**

## Политик системаны яңарту

**Ил башлыгы булсам, үземнең эшчәнлектә барысын да халык властен ныгытуга юнәлдерергә сүз бирәм.** Дәүләт идарәсе өлкәсендә дә, гомумхалык милеге белән идарә итүдә дә Россия халыкларының реаль тигезлеге тәэмин ителәчәк.

**Гражданнар ихтыярына каршы төшәргә беркем дә җөрьәт итмәячәк.** Мин сайлауларда тавыш бирү йомгакларын бозып күрсәтү фактларының барысын да җентекләп тикшерергә дип, хокук саклау органнарына кичекмәстән әмер бирәчәкмен.

2012 елның 1 декабренә чираттан тыш парламент сайлаулары уздыру билгеләнәчәк. Дәүләт Думасы депутатлары белән бер үк вакытта сезнең һәрберегез дә Федерация Советының яңа составын сайлауда шәхсән катнаша алачак.

Мин сезгә ачык һәм гадел сайлау системасы булдыруны гарантиялим. Илнең барлык сайлау комиссияләре дә Россиядә гамәлдә булган барлык партияләрнең вәкилләкләренә таянып оештырылачак. Сез политик партияләр җитәкчеләре һәм президентлыкка кандидатларның мәҗбүри катнашындагы тулы канлы теледебатлар күрә һәм ишетә алачаксыз. Тавыш бирү нәтиҗәләрен бозып күрсәткән өчен җәза чаралары да кырысрак булачак.

Парламентның вәкаләтләре һәм контрольлек итү функцияләре киңәя барачак. Президентлык итү срогы 5 елга кадәр калдырылачак. Россия гражданины президент постына ике тапкыр гына сайлана алачак, күбрәккә түгел. Илнең дәүләт башлыгы белән бергә сайлап куела торган вице-президенты вазыйфалары булдырылачак.

2012 ел ахырына кадәр мин Дәүләт Думасына губернаторларны турыдан-туры сайлап кую турындагы Закон проектын кертәчәкмен. Аларны сайлап кую өчен бердәнбер «җиз иләк» булып шул төбәктә яшәүчеләрнең фикере һәм политик партияләрнең ачыктан-ачык көрәше белән кандидатларның программасы торачак.

Бер ел эчендә Россиядә коррупциягә каршы махсус закон гамәлгә кертеләчәк.

2013 елда референдум турында яңа закон кабул ителәчәк. Властьны турыдан-туры кулда тоту өчен халыкның реаль мөмкинлекләре киңәячәк.

2014 елдан илдә җирле Советларның бердәм системасы эшли башлаячак. Җирле үзидарәләр ихтыяҗларын финанслау артачак.

2015 елдан башлап, шәһәрләрдә һәм районнарда халык судьялары халык тарафыннан сайлап куела башлаячак.

Сезнең җәмәгать оешмалары аша һәм халык контроле ярдәмендә властька йогынты ясау мөмкинлегегез булачак.

## Россиянең куркынычсызлыгы

Минем җитәкчелектә Халык ышанычына таяна торган Хөкүмәт яңа курс алачак. **«ӨЧ плюс ҖИДЕ плюс БИШ»** формуласы буенча эшләячәк программа түбәндәгеләрне үз эченә алачак:

**– тышкы политиканың ӨЧ яңа юнәлешен;**

**– яңа экономик политиканың ҖИДЕ юнәлешен;**

**– БИШ социаль өстенлекле юнәлешне.**

СССР таркалганнан соң дөнья реакциясе торган саен әрсезләнә бара. Дөньяны яңа баштан бүлү башланды: көнбатыш режимы басымы астында табигый ресурслар һәм сату базарлары яулап алына. АКШ берничә басып алу сугышы алып бара. Вашингтонның «Зур Якын Көнчыгыш» проекты – дөньяга баш булу планының бер өлеше генә әле ул. Безнең илгә теләсә нинди агрессиягә каршы тора алырлык калкан кирәк. Шуннан башка без Россиянең алга таба үсеше өчен уңай шартларны да, халыкка лаеклы тормышны да тәэмин итә алмаячакбыз.

*(Дәвамы 2-нче биттә)*

# КПРФтан һәм халык-патриотик көчләрдән Президентлыкка кандидат Г.А. ЗЮГАНОВның Россия гражданнары каршындагы йөкләмәләре

## (сайлау алды программасы)




Г.А. Зюганов Казанда.

Рәсми Мәскәү НАТОга каршы тору чараларын тәки эшләмәде. Ливиягә бәреп керү белән Россиянең фактта ризалашуы хурлыклы гамәлгә әверелде. АКШ җәелдергән кораллану процессына каплагыч кына булып торган СНВ-3 килешүе ратификацияләнде. Безнең илебезнең оборона потенциалы тизләтелгән рәвештә җимерелеп бара. Россия территорияләрен әрәм-шәрәм итү дәвам итә. Тугандаш Белоруссия читкә тибәрелә.

**Дәүләт куркынычсызлыгын торгызуны һәм Россиянең суверенитетын гарантияләүне бик мөһим дип саныйм.** Моның өчен без өч бурычны хәл итәчәкбез.

**1. Тышкы политиканың яңа өстенлекләре** дөнья аренасында гадел мөнәсәбәтләр булдыруга, союзниклар һәм Россиянең даими партнерлары санын арттыруга юнәлдереләчәк. Без бөтен көчне БМОның ролен күтәрүгә, күпкырлы дөньяны раслауга, НАТО йогынтысын чикләүгә юнәлтәчәкбез. Безнең чит илләрдәге ватандашларыбыз ышанычлы яклау табачак.

**2. Тугандаш халыкларның яңа союзын булдыру.**
СССР составына кергән илләрне үзара якынайту өчен мин мөмкин булганның барысын да эшләячәкмен. Россия, Белоруссия, Украина һәм Казахстанның бердәм экономик пространствосы булдырылачак. Без Белоруссия белән Россия дәүләтләренең ныклы союзын булдыруны тәэмин итәчәкбез.

**3. Илнең оборона куәтен ныгыту.**
Халык ышанычы Хөкүмәте Армия һәм Флотны «Сердюков тар-мар итүе»нә чик куячак. Без Россиянең Кораллы Көчләрен һәм оборона-промышленность комплексын торгызачакбыз. Офицерларның гаиләләре торак белән, мәктәпләр, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, мәдәният йортлары белән тулысынча тәэмин ителәчәкләр.

**Мин сезгә мөстәкыйль һәм тынычлык сөюче тышкы политика булдыруны, Ватаныбызны тышкы янаулардан саклауны тулы ышаныч белән вәгъдә итәм.**

## Экономик политика

«Реформалар» барган еллар эчендә Россия промышленность потенциалының өчтән ике өлешеннән артыграгы юк ителде. Җир асты байлыклары чыгару өстендә эшли торган 9850 промышленность предприятиесенең 416сы гына дәүләтнеке булып кала. Нәтиҗәдә олигархларның табышы табигый ресурсларны эксплуатацияләүдән алган бөтен илебез табышыннан 400 тапкырга артып китә. Менә ни өчен хәерчеләр саны кимеми, производство тармагы үлеп бара, ә инфраструктура күзгә күренеп тарала.

Бу хәлне кискен төстә үзгәртү кирәк. **«Скважина экономикасы»** (табигый байлыкларны сату) **урынына үсеш экономикасы булдыру өчен без җиде төрле бурычны хәл итәчәкбез.**

**1. Дәүләтнеке итү.**
Җир, Урман, Су кодекслары, Җир асты байлыклары турында Закон яңадан кабул ителәчәк. Алар табигый ресурсларны халык милке итеп беркетәчәк. Моннан тыш, дәүләтнеке итү политикасы нефть-газ комплексы, банклар эшчәнлеге, энергетика, авиатөзелеш, тимер юл транспорты тармакларына да кагылачак. Россия бюджеты керемнәре ике тапкырга артачак. Экономиканы торгызу өчен дә, социаль проблемаларны хәл итү өчен дә акча табылачак.

Ассызыклап әйтәм: бар нәрсәне дә дәүләт милке итеп күчерүнең мәгънәсе юк. Бигрәк тә сезнең хосусыйлаштырган квартирларыгыз, дача участоклары һәм башка шәхси мөлкәтегез турында сүз дә бармый. Дәүләтнеке итү процессы аерым бер тар даирә затларга кагылачак. Шул ук вакытта 90-нчы елларда халык байлыгын үзләштергән, әмма соңрак ул производствоны үстерә-киңәйтә алганнарга без лаеклы компенсация тәкъдим итәчәкбез. Бу кешеләрне без белгечләр сыйфатында эш белән тәэмин итәргә һәм, инвесторлар буларак, кызыклы проектларда катнашырга чакырырга әзер булачакбыз. Безнең команда диалогка һәм акыллы килешүләр төзүгә әзер, әмма олигархлар көен көйләп тормаячакбыз.

Мин сезгә гарантиялим: милекне дәүләтнеке итүдән, урта һәм кече бизнесны да кертеп, халыкның 99 проценты отачак. Күрерсез, хөкүмәт газга һәм электр энергиясенә, коммуналь-торак хезмәтләргә, транспорт чараларын кулланган өчен тарифларны арттырудан туктаячак, шулай ук күмер һәм ягулык-майлау материалларына бәяләр дә күтәрелүдән туктаячак. Шуның нәтиҗәсендә туклану продуктларының һәм башка төрле товарларның да бәяләре төшәчәк.

**2. Яңа индустриализация.**
Без «Тукталышсыз модернизация» принципы буенча эш итәчәкбез. 2013 елдан 2016 елга кадәр булган арада промышленностьны үстерүгә дәүләт инвестицияләре кимендә 20 триллион сумга артачак. Индустриализацияне без фәнни-техник прогрессның алдынгы казанышларына нигезләп үткәрәчәкбез. Бердәм энергетика системасы торгызылачак.

**3. Россия авылларын торгызу.**
Без азык-төлек белән тәэмин ителеш җәһәтеннән илнең куркынычсызлыгын кире торгызачакбыз. Авыл хуҗалыгы үсешенә ассигнацияләр федераль бюджет чыгымнарының 10 процентан алып, 15 процентына кадәр өлешен тәшкил итәчәк. Хөкүмәт зур күмәк хуҗалыклар оештыруны тәэмин итәчәк, крестьяннарга заманча техника бирәчәк. Бәяләр диспаритеты ниһаять бетереләчәк. Авылларда мәдәният йортлары, мәктәпләр, балалар бакчалары, больницалар һәм поликлиникалар торгызылачак. Без авылларга тулысынча газ кертеп бетерүне гарантиялибез.

**4. Финанс политикасын алыштыру.**
Бүгенге власть нефть долларларын үзләренә һәм банкирларына «мая» сыйфатында чит илләргә күчерә барып, экономиканың җелеген суыра, хәлсезләндерә. Безнең акча – кредит һәм финанс политикасы, шулай ук бәяләр ясалышына һәм тарифларга контрольлек итүебез үз илебездәге товар җитештерүчеләргә һәм муниципаль берәмлекләргә булышуны гарантияли.

Россия банк системасының нигезен, Внешторгбанк, Сбербанк, Стройбанк, Сельхозбанкны да кертеп, дәүләт банклары тәшкил итәчәк. Алар илнең финанс ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм нәтиҗәле акча әйләнешен тәэмин итәчәк. Коммерцияле банклар да сакланып калачак, аларның хезмәтләреннән файдалану экономик һәм социаль үсешне стимуллаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Кредит өчен алына торган коточкыч зур процентлары белән экономиканы буа торган спекуляция бетәчәк.

**5. Налог системасын кабат карау.**
Экономиканың реаль секторы предприятиеләре өчен налоглар кимeтеләчәк. Конкурентлыкка сәләтле продукция эшләп чыгара, фәнни-тикшеренү эшләренә, тәҗрибә-конструкторлык эшләренә средство бирә торган производство предприятиеләре сизелерлек льготалар алачак.

Без, бюджетны ел саен ике триллион сумга тулыландырып, керем налогының прогрессив шкаласын кертәчәкбез. Әмма гаиләгездәге һәр кешегә туры килә торган керем суммасы 12 мең сумнан кимрәк була икән, сез бу налогны түләмәячәксез.

**6. Фәннең тизләтелгән үсеше.**
Бүгенге көндә Россия экспортында югары технологияләр продукциясе өлеше инде 0,5 процентка кадәр кимеде. Германия белән Япониядә ул 30 проценттан артып китә, ә АКШта 40 процентка җитқән. Бу хурлыклы хәлдән котылу өчен без 2014 елга илдәге фән тармагын финанслау күләмен ике тапкыр арттырачакбыз. Совет власте торгызган фән корылмалары һәм фәнни үзәкләр илне торгызуда ышанычлы терәк булачаклар. Галимнәр хезмәтенә без лаеклы түләү, перспективалы яшь тикшеренүчеләргә – торак белән тәэмин итү, башка юллар белән ярдәм итүне гарантиялибез. Аспирантлар һәм докторантларның стипендиясе дүрт тапкырга артачак.

*(Ахыры 3-нче биттә)*

Россия фәне дәүләт политикасын эшләүдә актив катнаша башлаячак. Президент һәм Хөкүмәт хәлиткеч карарларның һәммәсен дә бары тик Югары интеллектуаль совет хуплавыннан соң гына кабул итәчәк.

**7. «Пространствоны буйсындыру» программасын гамәлгә ашыру.**

Россия авиатөзелешенә инвестицияләр инде 2013 елда ук ике тапкырга артачак. Без авиакомпанияләрне эреләндереп, заманча региональ авиация булдырачакбыз, очышларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен чаралар күрәчәкбез. Тиз йөрешле яңа магистральләр булдыруга да без зур игътибар бирәчәкбез. Диңгез һәм елга транспортын үстерү программалары эшли башлаячак. Йөрү тарифларын җайга салу сезгә хәрәкәт итү мөмкинлеген арттырачак.

Халык ышанычына таяна торган Хөкүмәт эшчәнлегенең беренче өч елында промышленность һәм авыл хуҗалыгы җитди капиталь салымнар таләп итәчәк. Әмма алар эшли башлагач, **экономик үсеш бюджетка җитди ышанычлы керемнәр бирә башлаячак. Бу исә зур масштаблы социаль программаларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.**



**КПРФ Үзәк Комитеты Председателе, РФ президентлыгына кандидат Г.А. Зюганов, «Татарстан коммунисты» газетасы баш редакторы, Зюгановның ышанычлысы, КПРФның Азнакай горкомы беренче секретаре Х.М. Гыйләҗев һәм Татарстан Дәүләт Советының КПРФ фракциясе җитәкчесе, партиянең Татарстан рескомы беренче секретаре Х.Г. Миргалимов.**



Г.А. Зюганов Түбән Новгородта Татарстан коммунистлары арасында. 16 июль, 2011 ел.

## Социаль һәм милли-мәдәни политика

Россия Президенты вазыйфаларын үтәүгә керешкәч, **мин бердәм социаль политика алып баруны, илебезнең барлык территорияләрендә дә культура кыйммәтләренә үтеп керү мөмкинлекләре булдыруны гарантиялим. Кешенең киңкырлы рухи үсеше властьның төп бурычы булып торачак.** Халыкны социаль яклауның югары стандартларын без, региональ һәм җирле бюджетларның керем дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, тәэмин итәчәкбез. Россия артта калган нокталарсыз илгә әйләнәчәк. Социаль политиканың бердәмлегә һәм халыклар дуслыгы дәүләтебезнең бөтенлеген ныгытачак. Русофобия һәм милләтара каршылыклар китереп чыгарырга омтылышның һәрбер очрагына кискен чик куелачак.

**1. «Социаль джунгли»га алмашка гаделлек җәмгыяте киләчәк.**

Без яңа Хезмәт кодексы кабул итәчәкбез һәм ялланып эшләүчеләрнең хокукларын яклаячакбыз. Хезмәт ияләре лаеклы эш шартларына һәм хезмәт хакы алып эшләячәккә, ял һәм сәламәтләндерүгә, белемен һәм культура дәрәҗәсен күтәрүгә гарантияле булачаклар.

Бер ел эчендә без илгә «Бердәм Россия» тарафыннан көчләп тагылган, халыкка каршы кабул ителгән барлык законнарны кабат карап чыгачакбыз. Беренчеләрдән булып, социаль өлкәне коммерцияләштерү турындагы 83-нче номерлы Федераль Законга тукталачакбыз. Яңа законнар социаль учреждениеләр челтәрен киңәйтәчәк, ана һәм бала хокукларын яклауны көчәйтәчәк, өлкән яшьтәгеләргә һәм инвалидларга ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләячәк. «Сугыш балалары» дигән махсус статус булдырылачак.

2013 ел ахырына Россиядә уртача пенсия күләме – 2, ә минималь пенсия 3 тапкырга артачак.

Безнең һәркайсыбыз лаеклы торак белән тәэмин ителәчәк. Аз керемле гаиләләр аны түләүсез алачак. Калганнар исә торакны еллык ставкасы 5 процентган артмаган суммага алачак. Кешеләрне тузган торактан һәм авария хәлендәге торактан яхшыларына күчерү буенча зур масштаблы программа эшли башлаячак. Индивидуаль торак төзелеше алып барырга телəүчеләргә, төзелеш өчен җир түләүсез бирелеп, дәүләт тарафыннан актив ярдәм күрсәтеләчәк.

Яңа Торак кодексы инфраструктураны һәм коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт карамагына кайтарачак. Идарәче компанияләр дә дәүләтнеке, яисә муниципалитетныкы булачак. Күп квартирлы йортларның коммуникацияләрен, түбәләрен, подвалларын һәм подъездларын ремонтлау өчен власть җавап тотачак.

Арзанлы җылылык һәм электр энергиясе һәр йортта булачак. Сезнең торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрегез гаилә кеременең 10 процентыннан артмаячак.

**2. Балалар һәм яшьләр дәүләт ярдәмен алачак.**

Яшьләргә без гарантиялибез: тулысынча түләүсез белем алуны, белгечлек буенча эш белән тәэмин итүне, аларның гаиләләрен түләүсез торак белән тәэмин итүне.

Ике ел эчендә без мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә урыннарга булган кытлыкны бетерәчәкбез. Күп балалы гаиләләр өчен ташламаларның киңәйтелгән системасы эшли башлаячак. Балаларны сәламәтләндерү, ял иттерүне оештыру программассы да сизелерлек киңәйтеләчәк.

Дәүләт сәләтле балаларга, яшь уйлап табучыларга, галимнәргә, перспективалы проект авторларына актив ярдәм күрсәтәчәк. Яңа спорт секцияләре, иҗади клублар һәм студияләр, туристлык үзәкләре ачылачак. Яшьләр һәм балалар берләшмәләренә һәр яклап теләктәшлек һәм ярдәм күрсәтеләчәк.

**3. Яхшы сыйфатлы белем алу мөмкинлеге һәркемгә биреләчәк.**

Без Совет властеның бөек казанышын – гомуми түләүсез белем алу мөмкинлеген халыкка кире кайтарачакбыз. Аңа дәүләт чыгымнары тулаем эчке керемнең 4 процентыннан алып, 8 – 10 процентына кадәр артачак. Остаз һәм укытучы хезмәтенә түләү лаеклы булачак, бу һөнәрнең абруе ныгыячак, үсәчәк.

Мәктәп укучылары түләүсез кайнар ризык белән тәэмин ителәчәк. Студентларның стипендия күләме дә, аны алучылар саны да артачак. Бу максатлар өчен билгеләнгән чыгымнар 2012 елның 1 сентябреннән ике тапкыр артык булачак, алга таба исә стипендия күләме ел саен индексацияләнәчәк.

**4. Халыкның сәламәтлеге ныгыячак.**

Сез яхшы сыйфатлы медицина ярдәмен бушлай ала башлаячаксыз. Хосусый клиникалар тулы куәткә эшләүче дәүләт сәламәтлек саклау системасына өстәмә рәвешендә генә булачаклар. Башкарылачак эшләр: авырып китүләрне комплекслы профилактикалау; санаторий-курортларда дәвалана алу мөмкинлеге; сәламәт тормыш рәвешен киң масштабта пропагандалау.

2014 елдан да соңга калмыйча, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы илдәге уртача күрсәткечтән югарырак булачак.

Яңа туган балага бер тапкыр бирелә торган пособие 2013 елның 1 гыйнварыннан 50 мең булачак. Бала өчен бирелә торган айлык пособие аның реаль яшәү минимумына тәңгәл булачак. 2015 елга без ана һәм бала сәламәтлеген саклау служдбасын, хатын-кызлар консультацияләре һәм бала тудырганда ярдәм күрсәтү учреждениеләренең эшен тулысынча торгызачакбыз.

**5. Власть илнең мәдәни күтәрелешен һәм рухи бердәмлеген тәэмин итәчәк.**

Дәүләт рухи кыйммәтләрне һәм Россиядәге барлык халыкларның милли традицияләрен яклаячак. 2012 ел ахырына кадәр «Культура турында» закон кабул ителәчәк. Өч ел эчендә бу максатка чыгымнар өч тапкыр артачак. Мәдәни һәйкәлләрне саклау чаралары көчәйтеләчәк. Без тарихыбызны үткән буын вәкилләре ирешкән казанышларны мәсхәрәләргә теләүчеләрдән ышанычлы саклаячакбыз. Илебез телевидениесенең интеллектуаль һәм рухи дәрәҗәсе күтәреләчәк. Сез инде үзәкка үткән телерекламалардан котылачаксыз. Русларның һәм Россиядәге барлык халыкларның телен, культурасын саклау буенча киң масштаблы программа эшли башлаячак. Иҗат берлекләре эшчәнлек өчен киң мөмкинлекләргә ия булачак.

## Алты елда мин өлгерәчәкмен

**Президентлык итү өчен алты ел вакытның бик җитди икәнлеген мин беләм. Бу вакыт эчендә хәлләрне уңай якка үзгәртергә, Россиянең тизләтелгән темплар белән үсешенә нигез салырга мөмкин.** Сезнең каршыдагы минем бу бурычларым – КПРФның сайлау алды программасында тәфсилләп язылган, озак перспективага йөз тоткан идеяләр тупланмасының бер өлеше генә әле.

Минем команда үз көченә нык ышана. Властька килсәк, без сайлау системасын информацион террордан, пычрак технологияләрдән һәм акча хакимлегеннән азат итәчәкбез. Гражданнарның ихтыяры, теләкләре чиновниклар басымыннан котылачак. Безнең максат – политик көрәшне чиста алып бару, ачыктан-ачык сөйләшүләргә һәм тигез хокуклы дискуссияләргә без һәрвакыт әзер.

Мин президент булып сайлангач, дәүләт аппараты сизелерлек кимиячәк, әмма нәтиҗәлерәк эшләячәк. Власть коррупциягә каршы рәхимсез көрәш башлаячак. Халык үзидарәсе һәм чиновниклар эшенә контрольлек итү һәр җирдә киң җәелдереләчәк. Мин гражданлык инициативасына һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлегенә актив булышачакмын. Сез төрле дәрәҗә депутатларны һәм башлыкларны, сайлау алды вәгъдәләрен үтәмәгән очракта, кире чакыртып алу хокукына ия булачаксыз. Власть алмашыну тәэмин ителәчәк. Кеше хокуклары якланган булачак.

**Мин ышанам: халыкның күпчелеге җиңәргә һәм үзенең гадел властен урнаштырырга бурычлы.**

**Без сезнең белән ирешелгән казанышлар өчен горурлана һәм киләчәккә ышанычлы карый торган илдә яши алабыз һәм шулай тиеш тә.**

**Геннадий ЗЮГАНОВ,**
**Россия Федерациясе**
**президенты постына кандидат.**

# Гадел сайлаулар өчен!



Казан

Шул исем астында 4 февральдә Казан, Чаллы һәм башка шәһәрләрдә митинглар булып узды. Аларда КПРФ вәкилләре белән рәттән, «Яблоко», «Правое дело» партияләреннән һәм башка иҗтимагый берләшмәләрдән дә катнашучылар күп булды. Казанның Мулланур Вахитов һәйкәле янында җыелган халык алдында КПРФның Татарстан рескомы беренче секретаре Х.Г. Миргалимов һәм КПРФ члены И.Г. Веселов чыгыш ясадылар. Игорь Веселов: «Татарстан «Бердәм Русия»гә иң күп тавыш бирүче буларак оятка калды. Чуров Татарстаннан үрнәк ала. Путин тагын президент булырга тели, безгә андый җитәкче кирәкми!» – дип сөйләде. Митингта катнашучылар РФ Дәүләт Думасына сайлау нәтиҗәләрен юкка чыгаруны, Чуров белән Путинны отставкага җибәрүне таләп иттеләр. 4 мартта булачак президент сайлауларында контрольне көчәйтергә чакырдылар.



Чаллы

# Сайлаулар – алдаулар…

4нче декабрьдә үткән сайлаулар Татарстан өчен хурлыклы тәмамланды: халыкның 80 процентка якыны «Бердәм Русия» партиясе өчен тавыш бирде. Ни өчен «хурлыклы»? Чөнки бу партия хакимияттә вакытта татар халкы зур югалтулар кичерде: 309нчы Федераль Закон нигезендә, безне милли мәктәпсез калдырдылар. Шулай итеп, ана телендә белем алудан мәхрүм иттеләр, бу исә килачәктә телнең юкка чыгуына китерергә мөмкин, ә тел юкка чыкса, милләт тә бетә. Путин һәм «Бердәм Русия» хакимияткә килгәч, илдә ислам диненә каршы ачыктан-ачык һөҗүм башланды: күпчелек ислам китаплары хөкем итеелде һәм закон белән тыелды, меңнәрчә мөселманнар бер гаепсезгә кулга алынды, төрмәләргә ябылды, ислам диненә килгән яшьләр төрлечә мәсхәрәләнде, кыйнап, гарип калдырылды… Ил буйлап террор гамәлләре башланды, махсус органнар оештырган шартлатулар мөселманнарга сылтанды, «антитеррор» битлеге астында дәүләт үзе ислам дине тоткан милләтләргә каршы террор башлап җибәрде.

Хакимияттә Владимир Путин һәм «Бердәм Русия» булган ун ел вакыт эчендә төбәк җитәкчеләрен сайлап куюлар бетте, шул исәптән, Татарстан Президентын да Мәскәү Кремле билгеләп куя башлады, инде сүз милли республикаларның үзләрен дә, президентларын да бетерү турында бара. Соңгы ун ел эчендә Русиядә демократиянең «д» хәрефе дә калмады, түрәләр karaклыкка һәм коррупциягә кереп батты, халыкның гаделлеккә ышанычы бетте. Русия халкы фәкыйрьләнеп, алданунның, талануның соңгы чигенә килеп җитте, өметсезлеккә төшкән милләт эчтән таркала, аягүрә чери башлады. Моннан соң ике генә юл калды: бетүең белән килешү, я башыңны күтәреп, сыртыңнан бу канэчкечләрне бәреп төшерү. Сайлаулар, вәзгыятьне фаҗигага әйләндермичә, тынычлык белән хәл итәргә юл ача иде…

Урыслар моны аңлады, бу сайлауларда хакимият партиясенә каршы тавыш бирделәр, Владимир, Вологда, Ярославль, Пермь төбәкләрендә «Бердәм Русия» иң аз тавыш җыйды, Себердә дә шул хәл күзәтелде. Бу сайлауларда «Бердәм Русия» партиясен хакимияттән алып ыргыту мөмкин иде, бу исә Путинның да җиңелүе була иде. Бу эшне эшләргә милли республикалар – Чечня, Ингушетия, Дагыстан, Татарстан, Башкортстан ирек бирмәде, алар «Бердәм Русия»гә 80-90 процент тавыш биреп, шушы хакимиятне саклап калдылар. Ни өчен? Югыйсә, без, урыслардан аермалы буларак, тел һәм дин ягыннан бик нык кыерсытылган идек һәм бу хакимияткә иң беренче булып без – милли республикалар каршы чыгарга тиеш идек. Әмма моның нәкъ киресе булды – үзен төрмәдә тотучы империяне, инде менә ничәнче тапкыр, урыс булмаган милләтләр, шул исәптән, татарлар да саклап калды…

Әлбәттә, бу сайлауларда хәрәмләшүләр, фальсификацияләр дә бик күп булды, әмма татар авыллары районырайоны белән, ярыша-ярыша «Бердәм Русия» партиясенә 99 процент тавыш бирде. Мондый «бердәмлек» бары тик бер хокуксыз колларда һәм бик надан, үз язмышына битараф халыкларда гына булырга мөмкин. Без шуның кайсы икән? Кемне алдадык дип беләләр? Үз-үзләрен алдыйлар, балаларының киләчәген урлыйлар бит! Кемнән куркалар? Нигә урыс куркымый, нигә татар курка? Нигә татар түрәләре үз урынлыкларын саклап калу өчен тырыша? Татар түрәләре бүгенге көндә Русияне дә, Татарстанны да, татар халкын да сакламый, ә үз байлыкларын саклап калу өчен көрәшә.

Әмма бүген – 21нче гасыр, һәм Русия халкы, бигрәк тә, урыслар бу алдаулар белән килешмәячәкләр. Русия халкы ачлыкка да, ялангачлыкка да, туңу-өшүләргә дә озак түзә, әмма үзен шул дәрәҗәдә алдауга, талауга, хокукларыннан мәхрүм итүгә түзмәячәк. Бигрәк тә интернет тәбендә утырган яшьләр, бу сайлау дигән фарстагы оятсыз алдаулар белән беркайчан да килешмәячәкләр, алар, хокукларын даулап, урамнарга чыгачак. Һәм чыгалар да. Алар хакимияткә дә киләчәк. Бәлки, моның өчен тагын канлы бәрелешләр булыр, корбаннар булыр, әмма Русия халкы 21нче гасырда гаделсезлек белән килешмәячәк. Димәк, бу сайлауларның дәвамы әле алда булачак…

Алда тагын сайлаулар – монысы инде Русия Президентын сайлау. Заманында без, татар милләтчеләре, Татарстанда Русия сайлауларын уздыртмас өчен, мәйданнарда ач яткан идек. Без 20 ел буе Русия сайлауларына бойкот игълан иттек, аларда катнашмадык. Ә халыкны, бугазына басып, эш, печән-салам белән куркытып, 20 ел буе сайларга мәҗбүр иттеләр. Бу сайлаулар шуны күрсәтте: татар халкы сәяси милләт түгел икән әле, ул үз язмышына битараф, аны башкалар кулына уйламыйча да тапшыра, хуҗалар әйтте дип, үз башына теләсә кемне сайлап куя, аннан үкереп елый… Гасырлар буе, еллар буе шушы фаҗига дәвам итә. Әлбәттә, мондый ваемсыз милләтнең киләчәге икеле. Үзенең дәүләте, теле, дине, азатлыгы, хокуклары өчен көрәшмәгән милләтне башкалар аяк астында тузан булу язмышы көтә… Татар халкын мондый куркыныч киләчәктән Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын!

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА,**
**тарих фәннәре кандидаты, язучы.**
(«Безнең гәҗит», 14.12.2011).

## Сайлау шаукымы

# Дегетле җиңү

Ел буе ыгы-зыгы килеп, шау-шу куптарып, массакүләм мәгълүмат чараларында, телевидение, газета, радиоларда сайлау алды дебатларын, төрле фиркаләрнең үзара тарткалашып бәхәсләшүләрен, бер-берсе өстенә пычрак атып ызгышуларын күреп, гарык булды Русия халкы. Ниһаять, «Сайлаулар» трагикомедиясе узып та китте. Билгеле, хакимият даирәләрендә дә, халыкта да: «Бердәм Русия» җиңәчәк, дигән фикер өстенлек итте. Бу алдан ук билгеле булды. Моннан бернинди сер ясап тормадылар. Интриганың хикмәте шунда: әлеге спектакльне уйнап бетерергә кирәк иде. «Дәүләт Думасы депутатлары халыктан башка гына үзләрен яңадан депутат итеп куйдылар», – дип әйттермәс өчен, халыкның авызын томалар өчен эшләнде бу сайлаулар фарсы. Үз-үзләрен депутат итеп куйдылар, дисәң дә әллә ни ялгыш булмас.

«Җиңү»гә килгәндә, алай бик үк чиста сала алмады «Бердәм Русия» көндәшләрен. Мәкерле, тыелган алымнар кулланып кына, хәрәмләшеп, аяк чалып кына екты. «Җиңү» мичкәсенең балына бер кашык дегет кенә салынмады. Әйтергә кирәк, ул мичкәнең яртысы дегет белән тулмады микән әле? Дөрес, совет чорында ук куркып калган халык «бәхетле тормыш» вәгъдә итүчеләрне сайлап кайтты. «Җиңгәннән» соңгы чыгышларында «Бердәм Русия» башлыклары: «Барсы да яхшы, әйбәт, демократик рәвештә чиста үтте», – дип мактансалар да, дегетле балның тамакларын әчеттереп торуы сизелде. Халыкны тәмам миңгерәтеп, хайваннар дәрәҗәсенә җиткереп, битарафландырып, «сайлауларга» куып китерүгә карамастан, сайлаучыларның яртысы диярлек килмәде. Монда зур аналитик, сәясәтче булу да кирәк түгел. Гади арифметиканың 4 гамәлен белгән кеше дә аңларлык. Барлык сайлаучыларның саны 108 млн кеше, дип әйттеләр. Шуларның 60,2%ы сайлауларга килгән, ә 40%ка якыны килмәгән. 42 млн сайлаучы участокларга бөтенләй аяк басмаган, дигән сүз. Коточкыч зур сан бит бу. Килгән сайлаучыларның 50%ка якыны башка 4 фиркане «сайлаган». Бу якынча 66 млн кеше килгән чыга. 30%ы гына «Бердәм Русия»не сайлаган бит. Килгән 66 млн кешене генә түгел, ә менә 108 млн сайлаучыны кертеп тә санасыннар иде. Ә калган 42 млн сайлауга килмәгәннәрне кая куярга? Аларны Русия гражданнары исемлегеннән сызып ташлаганнармы әллә? Булыр, бик мөмкин. Б. Ельцин: «Русия 50-60 млн кешене генә туйдырырлык хәлдә», – дигән иде. Кырып-себереп җыйганда да, шул 30%тан артык тавыш җыймады «Бердәм Русия» фиркасе.

Ә бит хакимияттәгеләр халыкны нык «эшкәрттеләр». Беренчедән, аларның пропаганда машинасы радио, газета, телевидение аша эшләде, аннан эреле-ваклы җитәкчеләрне мэриярларга, башкарма комитетларга, «Бердәм Русия» штабларына җыеп эшкәрттеләр. Тегеләре, үз чиратында, кайтып, кул астындагыларга кемне сайларга икәнлеген аңлатып, күрсәтмә бирде. Яшеренбатырын түгел, турыдан-туры «Бердәм Русия»не сайларга куштылар.

Агитаторлар, пропагандистлар итеп, Русиядә һәрвакыт интеллигенцияне файдаландылар. Күп очракта, укытучыларны. 8-10 мең сумга эшләп йөрүче укытучылар, фатирлар буенча йөреп, «Бердәм Русия»не сайларга өндәде. Чөнки аларга шулай кушылган иде.

Бер генә эшче, бер генә авыл кешесе, гомумән, халыкның үзеннән беркем дә юк яңа Думада. Банкир, олигарх, эре завод җитәкчеләре, губернатор, мэр, эре шәхси эшмәкәрләр, фиркалар лидерларыннан торган Дума депутатлары якларммы халыкны? Көн кебек ачык. Алар үзләрен генә кайгыртачак, законнарны да үзләренә файдалы итеп кенә ясаячак. Рәхәт бит, Мәскәүдә уңайлы зур фатирлар, льготалар, зур хезмәт хакы, гомумән, халык исәбенә балда, майда йөзү.

Ә халыкка килгәндә, әлегә хезмәт хакларын, стипендияләрне, пенсия, пособиеләрне, шулай ук 1 июльгә кадәр торак-коммуналь хуҗалыгы тарифларын, салымнарны да «туңдырдылар» туңдыруын. Тик монда да бу бер оста алым гына.

Мин сайлау участогына якынлашканда, чит ил музыкасы үкерә иде. Мәктәп ишек төбендә 3-4 полиция хезмәткәре әрле-бирле йөренә. Ашамлыклар тулы өстәл артында чират юк. Халыкның йөзендә – битарафлык. Барысы да үз эченә бикләнгән. Һәркемнең үз мәшәкате, үз проблемасы.

Кайтып житеп, подъездга кергәндә, идәндә аунап ятучы агитплакатлар тау кадәр иде, дисәң дә ялгыш булмас. Лифт эчендә зур бер плакат эленеп тора. Аны ертырга, кубарып алырга маташканнар булса кирәк, тик шәп ябыштырылган, кубарып ала алмаганнар. Плакатта симез аю сурәте. Аркасындагы акча капчыгы «Бердәм Русия»нең буш вәгъдәләрен искә төшереп, җилфердәп тора. Ә ул плакатта: «Единая Россия – партия воров и жуликов!» дигән сүзләр ярылып ята…

**Рәис ЯКУПОВ. Чаллы шәһәре.**
(«Безнең гәҗит», 1.02.2012).

КПРФ
Информационный бюллютень «Татарстан Республикасы коммунисты»

Заказчик: кандидат на должность Президента Российской Федерации Зюганов Геннадий Андреевич. Оплачено из средств избирательного фонда кандидата на должность Президента Российской Федерации Зюганова Геннадия Андреевича. Изготовитель: ОАО «Бугульминская типография», адрес: 423230, Республика Татарстан, г. Бугульма, ул. Карла Маркса, д. 32. ИНН 1645014198. Заказ 302. Тираж 50 000 экз. Дата выпуска: 10.02.2012 г.
Ответственный за выпуск – Х.М. Гилязов, член Союза журналистов Российской Федерации и Республики Татарстан.